СОВЕТ МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

26.10.2022　　　　с. Майдан　　　　№ 23-122

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылы торак пункты территориясендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Мәйдан җирлеге Уставы нигезендә, Мәйдан авылы торак пунктының бер өлешендә яшәүчеләр төркеме инициативасын караганнан соң.

Югары Ослан муниципаль районының
Мәйдан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авылы җирлеге Мәйдан авылы территориясендә гражданнар үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 11 ноябрендә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2022 елда Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Мәйдан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Мәйдан авылының торак пункты территориясендә юлларны ремонтлау өчен, товарны китерү өчен билгеләнгән пунктка кадәр илтеп җиткерүче хисабына вак таш сатып алу.

«ӘЙЕ»　　　　　　　　　　　　«ЮК»

3. Мәйдан авылы территориялсенең өлешендә Яшьләр урамы, 1 нче йорт янында 9.00 сәгатьтә, 1 нче май урамы 14 нче йорт янында10.00 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев